**Тема: Тугъры дус - җан азыгы**

**Максат:**

1. Дуслашу өчен кирәк булган сыйфатларга ия булуның асылына төшендерү.
2. Укучыларны "Тугъры дус - җан азыгы" дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп тормышта яхшы дус табарга ярдәм итү.
3. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.
4. Матур яшәү өчен дуслаша белү сыйфатлары тәрбияләү.

**Сыйныф сәгатенең көтелгән нәтиҗәсе:**

- Аллаһы Тәгалә кешеләргә дусларча гына түгел, ә бәлки туганга караган шикелле якын итеп карарга, бер- берсенә ярдәмләшергә кушканны аңлау.
- Дустың синнән дә әйбәт булуының һәм аның кадерен белүенең асылына төшенү.
- Дуслык нык булсын өчен, үзеңә бик тырышырга кирәклеген аңлау.

**Эпиграф:** ***"Дусларны бик сайлап кына эзләргә кирәк- дустың синнән әйбәт булсын. Дуслык нык булсын өчен, үзеңә дә бик тырышырга кирәк".***

**Дәрес барышы.**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

- Кечкенә генә хикәяне тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

*Бер йегет үзенең дуслары күп булуы белән бик нык горурланган. Мәхәбәтен очраткач, йөләнешергә көн билгеләп куйган. Туйга әзерләнгәндә, аңа этиси дә булышкан. Башка эшләр арасында туйга чакыру открыткаларын тарату да әтисенә кушылган иде.*

*Туй көне җиткәч, кызыганычка каршы, мәҗелескә йегетнең бер дусты да килмәгән. Әтисен бик ачуланып:"Минем дусларымны ник чакырмадың?"дип әйткән. Әтисе:"Мин чакырдым, ләкин чакыру открыткасы урынына синең исемеңнән ярдәм сорап язу җибәрдем".*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Димәк, бүгенге дәрестә сүз нәрсә турында барачак?
- Чын һәм ялган дуслык турында. (Тугры дус - җан азыгы).
- Ни өчен егетнең дуслары ярдәм сорап җибәрелгән язуга җавап бирмәгәннәр?
- Алар чын дуслар түгел.
- Хикәянең героена бәя бирегез: ул үзе чын дусмы, юк микән?
- Ни өчен ул үзе дә чын дус түгел дип уйлыйсыз?

**III.Уку мәсьәләсен чишү.**

**1. Төркемнәрдә эшләү.**

**1нче бирем** ***" Эпиграф өстендә эш"***

*"Дусларны бик сайлап кына эзләргә кирәк- дустың синнән әйбәт булсын. Дуслык нык булсын өчен, үзеңә дә бик тырышырга кирәк"*- дигән сүзләрне эпиграф итеп тактага яздык.

- Ни өчен шулай булырга тиеш? Ә дустың синнән начар, ямьсез холыклы икән- нәрсә була?

Алдагы җөмләне дәвам итеп карыйк: "Әгәрдә минем дустым миннән начаррак булса, ..."

- "Дуслык нык булсын өчен, үзеңә дә бик тырышырга кирәк" дигән сүзне ничек аңлыйсыз? /Фикерләшү/

**2нче бирем** ***Уен "Мин башлыйм, син дәвам ит"***

- Дус, дуслык сүзләре белән бәйләнешле мәкальләр белән танышу (мәкальләрне тәрбияче башлый, укучылар дәвам итә).

- Дусны ашыкмыйча гына сайла, ...тапкач – *тиз алыштырма.*
- Әйт дустыңны – әйтермен үзеңнең ... *кемлегеңне.*
- Йөз сум акча булганчы – йөз ... *дустың булсын.*
- Дус көйдереп әйтер, дошман ... *көлдереп әйтер.*
- Дусларны бәхет бирә, ә бәхетсезлек ... сыный.
- Юләр дустың булудан акыллы дошманың ... *артык.*
- Дусларыңны рәнҗетсәң, дошманнарың ... *куаныр.*
- Кайсы мәкаль сезгә күбрәк ошый? Ни өчен?

**3нче бирем "*Ситуациягә бәя бирү*"**

*- Бу чынан да булган вакыйга турында гаҗит битләрендә бер ничә ел өлек укыган идем:*

*Тайга. Кыяшлы салкын көн.Унбишь яшьлек Валера, җиде яшьлек Сергей һәм бишь яшьлек Саша авыл янында тайгага терәлеп торган зур тауга чана шуарга дип чыгып китеп, туйганчы шунда уйнылар. Кич җитәрәк, Сергей белән Саша өйгә кайтырга кирәк дип карасалар- аларны бу тауга ияртеп алып килгән Валера юкка чыккан. Кайтырга кирәк, ләкин кайтып булмый,чөнки бергә килгән иптәшләре юк. Әти- әниләренә нинди җавап бирербез дип борчылып:"Әллә без тауның бер ягында уйнаганда, Валера тайганың урманына кереп киткән микән?"- дип уйлылар да, кара урманга кереп китәләр.*

*Тигендә- монда барып карыйлар- иптәшләре күренми.Тайгага өчкәрәк керәп үзләре сизмәстән адашалар. Бишь яшьлек Саша бик тиз арый, атларга теләми, карга утырып йоклыйсы гына килә аның.Себердә туып үскән Сергей әтисенән ишетеп бик яхшы белә: кыш көне агачка сөялепме, карга утырыпмы йокласаң, бу суыкта катып үләсең. Кесәсендә булган бер конфетны икегә бүлеп иптәшенә бирә һәм кечкенә дустына йокларга ирек бирми: җиләкәсеннән җилтерәтә, аны атларга мәҗбүр итә.*

*Ә инде кояш баеый. Ике малайның әти- әнисе Валераның өйенә йөгерәләр. Ул индә күптән өйдә- чәй эчеп утыра. Кечкенә дусларына бер сүз әйтмичә кайтып киткән икән. Авылдашлары бергә җыелып, фонарьлар яндырып, тайгада балаларны эзлиләр һәм тамам хәлсезләнгән, ләкин хаман атлап барган малайларны табалар. Җиде яшьлек Сергей кечкенә дустын да,үзен дә кышкы суыкта катып үлүдән кыткарып алып кала һәм безгә чын дусның нинди булырга тиеш икененә үрнәк бирә.*

- Бу вагыйгага нинди исем кушар идегегез?/Тугъры дус/
- Кайсы мәкаль хикәянең төп фикерен ачыклый?
- Дусларны бәхет бирә, ә бәхетсезлек сыный.
- Ни өчен шулай дип уйлысыз?
- Бу мәкаль бүгенге дәреснең эпиграфы буларак тактада язылган.

**4нче бирем "*Яхшы дусның сыйфатларын әйтеп бирегез*"**

- Сез үзегезнең дустыгыз шудый булсын дип теләр идегезме? Ни өчен?
- Нинди кешене без дус дип атыйбыз? Укучыларның җаваплары тыңланыла:
- Ул сиңа тугры, сине авырлыкта ташламый, ярдәмгә килә.
- Серләрне саклый белә.
- Юк- барга үпкәләми, ачуланмый.
- Ул сине аңлый, вак- төяк кимчелекләрне гафу итә.
- Башка кешеләр янында гаепләреңне сөйләми, ләкин үзеңә ялгышларны

- йөмшак итеп күрсәтә.
- Дус үз гаепләрен таный белә.
- Синең фикерләреңне хөрмәт итә.
- Нәрсә ул дуслык?

- Ихтыяҗларның, карашларның, фикерләрнең уртаклыгына, үзара рухи якынлык, бер-береңне ихтирам итү һ.б. хисләргә нигезләнгән мәхәббәт. – Халыклар дуслыгы, иҗади дуслык. Берәр нәрсә белән артык мавыгу, аны ярату хисе. – Китап белән дуслык урнаштырдым.

**2. Безнең киңәшләр.**
- Үзеңә дус сайлаганда, эзләгәндә менә боларны исеңдә калдыр:
*1. Дустың акыллы булсын.* Чөнки татар халкында шундый мәкаль дә бар: “Дустың үзеңнән яхшырак булсын”.
*2. Дустың күркәм әхлаклы булсын.* Дустыбыз безне һаман яхшылыкка өндәп, начар эшләрдән тукта торган кеше булырга тиеш.
*3. Дустың киңәш бирүче, хаталарыбызны күрсәтеп төзәтүче,* кирәк вакытта безне тәнкыйть итүче кеше булсын.
*4. Дустың серләрне саклаучы булсын.* Кеше үзара сөйләшеп, кайгы – шатлыкларын, серләрен дуслары белән уртаклашып күңелен бушатасы килгән вакытлары була. Кеше, серләрен дуслары белән уртаклашса, күңеле тынычлап кала. Дус кеше мондый очракларда игътибар белән тыңларга, кирәк булганда ярдәм итәргә, сер саклый белергә тиеш.
*5. Дустың динле һәм ышанычы көчле булсын.* Дус итеп сайлаган кешенең динле һәм әдәпле булуы кирәк, чөнки динсез кеше үз – үзенең дошманыдыр. Үз – үзенә дошман булган кеше башкаларга чын дус була алмый. Ә кем сон ул чын дус?
- Чын дус – эшебез төшкәндә ярдәмче, ялгызлык килгәндә хәлебезне белә торган кешеләр. Дусны тапкач саклый белергә дә кирәк. Дуслыкны саклау өчен нинди сыйфатларга ия булырга кирәк? (Җаваплар: түземле , сабыр, вәгъдәле, ихлас күңелле).

**3. Галимгә сүз бирәбез.**

- К.Насыйриның “Китаб-әт-тәрбия” китабының ачып укыйк:
*“Бер хәким үзенең углына әйтте: “Әй угыл, кемне теләсәң, аның белән сөйләш, мөгамәлә кыйл, йөреш, кунакка чакыр, үзең бар. Әмма <u>биш төрле кемсәнә</u> (кеше белән) <u>аралашма.</u> Әүвәл (иң беренче)* ***ялганчы кеше*** *белән әңгәмә кыйлма, чөнки ялганчы кешенең сүзе су өстенә ялган язган кебектер, ышанычы юктыр, якынны ерак кыйдыр, еракны якын итәр. Дәхи* ***ахмак вә надан*** *күренсә дә, вакыйгадан, зарардыр. Вә дәхи* ***комсыз*** *кеше белән аралашма. Чөнки ул кеше гел синнән өмет итеп кенә торыр. Янә дәхи* ***саран*** *кеше белән юлдаш булма. Чөнки саран кеше сиңа һичбер зарардан хали (буш ирекле) булмас. Әгәр дә аңар хаҗәтең төшсә, сине кимсетер вә хур кыйлыр. Хосусән, сәфәрдә саран кеше белән юлдаш булма. Дәхи вә* ***куркак вә җебегән*** *белән аралашма, чөнки куркак кеше белән һич имин булмассың”.*
- Чын дустыгызда нинди сыйфатлар булмаска тиеш? (ялган, наданлык, комсызлык-саранлык, куркаклык- җебегәнлек).

**4. Үгет- нәсыйхәтләр.**
- Ризаэддин Фәхреддин дуслык турында болай дигән:
- Адәм баласының шатлык вә кайгы вакытларында таяначак җире, файда күрсәтеп, файда күрәчәк урыны, дуслары булачактыр.
- Дине бөтен, гакылы камил, нәсел-нәсәбе асыл, фикере тугры, әдәбе җирендә булган кешеләрне табыгыз! Мойдый кешеләр авыруыгызда— дәва, сәламәтлегегездә — зиннәт, мәшәкатьләрегездә — таяныч, боек сәгатьләрегездә рәхәтләндерүче

булырлар. Мондый кешеләр еракка китүегездә — хәлегезне кайгыртучы, якын торганда сезнең хакыгызда догачы булырлар, байлыкка ирешү белән араны өзмәсләр, тарлыкка төшү белән аерылмаслар, дуслары — сүзләреннән артык фигыль вә гомерләрендә күрелер, олы изгелекләрне — кече дип санарлар, аз изгелекләрне олы күрерләр.

- Әгәр дә дөрес дусларыгыз булса, аларга ныгытып ябышыгыз, үзегездә шикаять итәрлек кимчелек булдырмагыз, аларны чын күңел белән сөегез, ахирәттә җыелу шарты белән, арагызны үлемнән башка нәрсә аермасын!
- Дуслык күрсәтүчеләрнең барчасы белән дә дус булмагыз, дошманлыгы бардыр дип уйлаган кешеләрегезнең барчасын да дошман санамагыз! Дуслыгының дөреслегендә шөбһә булган кеше белән дус булудан, һич дуссыз тору яхшы икәнлекне онытмагыз!
- Дусларыгызны шелтәләргә ашыкмагыз, туганнарыгыз вә кардәшләрегез белән бозылышуны җиңел күрмәгез; бәлки бу эшләрдә беркадәр сабыр булыгыз, чөнки ачуланышырга ният иткән кешеләрегез белән ачуланышмыйча вә бозылышмыйча, бер-ике көн кадәр сабыр итеп торсагыз — күп вакыт булыр, мондый ниятнең хата икәне ачылыр да, сабыр итүегез өчен үзегез дә шатланырсыз.
- Бик олы сәбәпләр булмаганда дуслар белән бозылышу — әдәпсезлектер. Шуның өчен аз гына нәрсәләр хакында дусларыгыздан аерылмагыз!
- Һәрвакыт хөрмәт күрсәтеп тору вә дөреслекне олылау сәбәпле дуслык көчәер. Шуның өчен дусларыгызга һәрвакыт ярдәмче вә аларга таяныч булыгыз! Кеше — бер ялгызы аз булса да, дуслары белән күп булыр. Дуслар — авырлык вә мәшәкать көннәрендә ярдәмче булсыннар өчендер.
- Бозык кешеләргә катышмагыз, алар юлына кермәгез, алардан бигрәк сак булыгыз, чөнки аларның иң ләззәтле эшләре бозыклык итү вә адәм балаларын һәлакәткә төшерү булыр. Адәм баласы ашамыйча вә эчмичә тора алмаган кебек, күңеле бозык булганнар да усаллык итмичә тора алмаслар. Әмма яхшы бәндәләр, тәмам боларның киресенчә булыр. Шуның өчен яхшы бәндәләр юлларына керегез вә алар белән дус булыгыз!
- Бозык кешеләргә катышу бик зарарлы булса да, алар белән дошман да булмагыз, бәлки вакыты җиткәнче йомшак мөгамәләдә булыгыз, бу сәбәпле аларның зарарыннан имин булырсыз!

**5. Психологлар: чын дуслыкның 13 кагыйдәсе.**

1) яңалыклар, әһәмиятле вакыйгалар белән уртаклашырга;
2) аның уй- фикерләрен, хисләрен “ярты сүз белән” аңларга;
3) кирәк чакта бик теләп ярдәм итәргә;
4) дустыңа син барында рәхәт булсын дип тырышырга;
5) дустыңа һәрвакыт ышаныч белән карарга;
6) дустың янында булмаса да, аны яманласалар- якларга;
7) алган әйберне, акчаны кире кайтарырга;
8) башка дус- иптәшләрен кабул итәргә;
9) вак- төяк белән аптыратмаска;
9) кеше барында дусның кимчелекләрен күрсәтмәскә;
10) дусның серен саклый белергә;
11) көнләшмәскә;

12) кирәкмәс җирдә өйрәтеп тормаска;

13) дусның вакытын сарыф итмәскә, теләкләрең хөрмәт итәргә.

**6. Изге Коръән китабыннан.**

- Аллаһы Тәгалә әйтте:

- ***“Мөселманнар бер- берсенә якын кардәшләр һәм туганнар”.***
- ***“Мөэминнәр (чын мөселманнар), әлбәттә, бер- берсенә кардәшләрдер. Кардәшләрегезнең арасын килештерегез, төзәтегез, Аллаһтан куркыгыз, мөэминнәр арасында фетнә, дошманлык салудан сакланыгыз, шаять, Аллаһтан рәхмәт ителерсез”*** */Хуҗ- җүрат: 10/.*

**7. Хәдисләр.**

- Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) хәдисен укып, үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с) әйтә:

- *“Инсаннар (кешеләр) җәмгыяте бер инсан (кеше) тәнендәге әгъзаларга охшар. Тәндә булган әгъзалар бер-берсенә ярдәмче булып торулары, берсе эштән чыкса, башкалары да шуннан зарар күрүләре кебек, инсаннар да бер-берсенә ярдәмче булып торырга һәм берсенә килгән һәлакәтне башкалары да уртаклашып сызланырга тиешләр”.*
- *"Бер кеше бер мөселманның дөньялык мәшәкатьләреннән бер мәшәкате хакында сөендерсә һәм юатса, Аллаһы Тәгалә аның ахирәт мәшәкатьләреннән бер мәшәкате хакында сөендерер. Бер кеше фәкыйрь һәм бурычланган кешегә дөньялыкта берәр төрле җиңеллек эшләсә (булышса һәм ярдәм бирсә) Аллаһы Тәгалә ул кешегә дөньяда һәм ахирәттә җиңеллек бирер. Бер кеше бер мөселманның гаебен һәм хата эшен пәрдәләсә, Аллаһы Тәгалә аны дөньяда һәм ахирәттә пәрдәләр. Үз кардәшенә ярдәм итүче кешегә Аллаһы Тәгалә ярдәм итәр".*

- Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз?

- Ислам безгә бер- беребезгә дусларча гына түгел, ә бәлки туганга караган шикелле якын итеп карарга, бер- беребезгә ярдәмләшергә куша.

**V. Рефлексия (Йомгаклау).**

**-** Дәреснең темасын искә төшерегез.

- Дуслык темасына карата нинди гыйбрәтләр алдыгыз? (Дусларны бик сайлап кына эзләргә кирәк- дустың синнән әйбәт булсын.).

- Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз? (Дуслык нык булсын өчен, үзеңә бик тырышырга кирәк).

- Чын дус сүзен сез ничек аңлыйсыз?

- Эчкерсез, аңа ихлас бирелгән.

- Холкы күркәм, күңеле яхшы булган кеше.

- Чын дус йөз елдан соң да дус булыр. Яхшы киңәш әйтсә генә дусны чын диеп була.

- Чын дус алдыңда мактамас, артта мактар, кирәк вакытта сине яклар.

**VI. Өйгә эш:** Өй эшен вариантлап бирәбез: 1) “Чын дус- нинди ул?” дигән темага җавап әзерләп килергә. 2) Чын дус турында хикәя, хәдисләрне эзләп табу.

**Тема: Тугъры дус - җан азыгы**

**Максат:**

5. Дуслашу өчен кирәк булган сыйфатларга ия булуның асылына төшендерү.
6. Укучыларны "Тугъры дус - җан азыгы" дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп тормышта яхшы дус табарга ярдәм итү.
7. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.
8. Матур яшәү өчен дуслаша белү сыйфатлары тәрбияләү.

**Сыйныф сәгатенең көтелгән нәтиҗәсе:**

- Аллаһы Тәгалә кешеләргә дусларча гына түгел, ә бәлки туганга караган шикелле якын итеп карарга, бер- берсенә ярдәмләшергә кушканны аңлау.
- Дустың синнән дә әйбәт булуының һәм аның кадерен белүенең асылына төшенү.
- Дуслык нык булсын өчен, үзеңә бик тырышырга кирәклеген аңлау.

**Эпиграф:** ***"Дусларны бик сайлап кына эзләргә кирәк- дустың синнән әйбәт булсын. Дуслык нык булсын өчен, үзеңә дә бик тырышырга кирәк".***

**Дәрес барышы.**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

- Кечкенә генә хикәяне тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

*Бер йегет үзенең дуслары күп булуы белән бик нык горурланган. Мәхәбәтен очраткач, йөләнешергә көн билгеләп куйган. Туйга әзерләнгәндә, аңа әтиси дә булышкан. Башка эшләр арасында туйга чакыру открыткаларын тарату да әтисенә кушылган иде.*

*Туй көне җиткәч, кызыганычка каршы, мәҗелескә йегетнең бер дусты да килмәгән. Әтисен бик ачуланып:"Минем дусларымны ник чакырмадың?"дип әйткән. Әтисе:"Мин чакырдым, ләкин чакыру открыткасы урынына синең исемеңнән ярдәм сорап язу җибәрдем".*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Димәк, бүгенге дәрестә сүз нәрсә турында барачак?
- Чын һәм ялган дуслык турында. (Тугры дус - җан азыгы).
- Ни өчен егетнең дуслары ярдәм сорап җибәрелгән язуга җавап бирмәгәннәр?
- Алар чын дуслар түгел.
- Хикәянең героена бәя бирегез: ул үзе чын дусмы, юк микән?
- Ни өчен ул үзе дә чын дус түгел дип уйлыйсыз?

**III.Уку мәсьәләсен чишү.**

**1. Төркемнәрдә эшләү.**

**1нче бирем *" Эпиграф өстендә эш"***

*"Дусларны бик сайлап кына эзләргә кирәк- дустың синнән әйбәт булсын. Дуслык нык булсын өчен, үзеңә дә бик тырышырга кирәк"*- дигән сүзләрне эпиграф итеп тактага яздык.

- Ни өчен шулай булырга тиеш? Ә дустың синнән начар, ямьсез холыклы икән- нәрсә була? Алдагы җөмләне дәвам итеп карыйк: "Әгәрдә минем дустым миннән начаррак булса, ..."
- "Дуслык нык булсын өчен, үзеңә дә бик тырышырга кирәк" дигән сүзне ничек аңлыйсыз? /Фикерләшү/

**2нче бирем *Уен "Мин башлыйм, син дәвам ит"***

- Дус, дуслык сүзләре белән бәйләнешле мәкальләр белән танышу (мәкальләрне тәрбияче башлый, укучылар дәвам итә).

- Дусны ашыкмыйча гына сайла, ...тапкач – *тиз алыштырма.*
- Әйт дустыңны – әйтермен үзеңнең ... *кемлегеңне.*
- Йөз сум акча булганчы – йөз ... *дустың булсын.*
- Дус көйдереп әйтер, дошман ... *көлдереп әйтер.*
- Дусларны бәхет бирә, ә бәхетсезлек ... сыный.
- Юләр дустың булудан акыллы дошманың ... *артык.*
- Дусларыңны рәнҗетсәң, дошманнарың ... *куаныр.*
- Кайсы мәкаль сезгә күбрәк ошый? Ни өчен?

**3нче бирем "*Ситуациягә бәя бирү*"**

*- Бу чынан да булган вакыйга турында гаҗит битләрендә бер ничә ел өлек укыган идем:*

*Тайга. Кыяшлы салкын көн.Унбишь яшьлек Валера, җиде яшьлек Сергей һәм бишь яшьлек Саша авыл янында тайгага терәлеп торган зур тауга чана шуарга дип чыгып китеп, туйганчы шунда уйнылар. Кич җитәрәк, Сергей белән Саша өйгә кайтырга кирәк дип карасалар- аларны бу тауга ияртеп алып килгән Валера юкка чыккан. Кайтырга кирәк, ләкин кайтып булмый,чөнки бергә килгән иптәшләре юк. Әти- әниләренә нинди җавап бирербез дип борчылып:"Әллә без тауның бер ягында уйнаганда, Валера тайганың урманына кереп киткән микән?"- дип уйлылар да, кара урманга кереп китәләр.*

*Тигендә- монда барып карыйлар- иптәшләре күренми.Тайгага өчкәрәк керәп үзләре сизмәстән адашалар. Бишь яшьлек Саша бик тиз арый, атларга теләми, карга утырып йоклыйсы гына килә аның.Себердә туып үскән Сергей әтисенән ишетеп бик яхшы белә: кыш көне агачка сөялепме, карга утырыпмы йокласаң, бу суыкта катып үләсең. Кесәсендә булган бер конфетны икегә бүлеп иптәшенә бирә һәм кечкенә дустына йокларга ирек бирми: җиләкәсеннән җилтерәтә, аны атларга мәҗбүр итә.*

*Ә инде кояш баеый. Ике малайның әти- әнисе Валераның өйенә йөгерәләр. Ул индә күптән өйдә- чәй эчеп утыра. Кечкенә дусларына бер сүз әйтмичә кайтып киткән икән. Авылдашлары бергә җыелып, фонарьлар яндырып, тайгада балаларны эзлиләр һәм тамам хәлсезләнгән, ләкин хаман атлап барган малайларны табалар. Җиде яшьлек Сергей кечкенә дустын да,үзен дә кышкы суыкта катып үлүдән кыткарып алып кала һәм безгә чын дусның нинди булырга тиеш икененә үрнәк бирә.*

- Бу вагыйгага нинди исем кушар идегегез?/Тугъры дус/
- Кайсы мәкаль хикәянең төп фикерен ачыклый?
- Дусларны бәхет бирә, ә бәхетсезлек сыный.
- Ни өчен шулай дип уйлысыз?
- Бу мәкаль бүгенге дәреснең эпиграфы буларак тактада язылган.

**4нче бирем "*Яхшы дусның сыйфатларын әйтеп бирегез*"**

- Сез үзегезнең дустыгыз шудый булсын дип теләр идегезме? Ни өчен?
- Нинди кешене без дус дип атыйбыз? Укучыларның җаваплары тыңланыла:
- Ул сиңа тугры, сине авырлыкта ташламый, ярдәмгә килә.
- Серләрне саклый белә.
- Юк- барга үпкәләми, ачуланмый.
- Ул сине аңлый, вак- төяк кимчелекләрне гафу итә.
- Башка кешеләр янында гаепләреңне сөйләми, ләкин үзеңә ялгышларны

- йөмшак итеп күрсәтә.
- Дус үз гаепләрен таный белә.
- Синең фикерләреңне хөрмәт итә.
- Нәрсә ул дуслык?

- Ихтыяҗларның, карашларның, фикерләрнең уртаклыгына, үзара рухи якынлык, бер-береңне ихтирам итү һ.б. хисләргә нигезләнгән мәхәббәт. – Халыклар дуслыгы, иҗади дуслык. Берәр нәрсә белән артык мавыгу, аны ярату хисе. – Китап белән дуслык урнаштырдым.

**2. Безнең киңәшләр.**
- Үзеңә дус сайлаганда, эзләгәндә менә боларны исеңдә калдыр:
*1. Дустың акыллы булсын.*Чөнки татар халкында шундый мәкаль дә бар: “Дустың үзеңнән яхшырак булсын”.
*2. Дустың күркәм әхлаклы булсын.* Дустыбыз безне һаман яхшылыкка өндәп, начар эшләрдән тукта торган кеше булырга тиеш.
*3. Дустың киңәш бирүче, хаталарыбызны күрсәтеп төзәтүче,* кирәк вакытта безне тәнкыйть итүче кеше булсын.
*4. Дустың серләрне саклаучы булсын.* Кеше үзара сөйләшеп, кайгы – шатлыкларын, серләрен дуслары белән уртаклашып күңелен бушатасы килгән вакытлары була. Кеше, серләрен дуслары белән уртаклашса, күңеле тынычлап кала. Дус кеше мондый очракларда игътибар белән тыңларга, кирәк булганда ярдәм итәргә, сер саклый белергә тиеш.
*5. Дустың динле һәм ышанычы көчле булсын.* Дус итеп сайлаган кешенең динле һәм әдәпле булуы кирәк, чөнки динсез кеше үз – үзенең дошманыдыр. Үз – үзенә дошман булган кеше башкаларга чын дус була алмый. Ә кем сон ул чын дус?
- Чын дус – эшебез төшкәндә ярдәмче, ялгызлык килгәндә хәлебезне белә торган кешеләр. Дусны тапкач саклый белергә дә кирәк. Дуслыкны саклау өчен нинди сыйфатларга ия булырга кирәк? (Җаваплар: түземле , сабыр, вәгъдәле, ихлас күңелле).

**3. Галимгә сүз бирәбез.**

- К.Насыйриның “Китаб-эт-тәрбия” китабының ачып укыйк:
*“Бер хәким үзенең углына әйтте: “Әй угыл, кемне теләсәң, аның белән сөйләш, мөгамәлә кыл, йөреш, кунакка чакыр, үзең бар. Әмма биш төрле кеше белә) аралашма. Әүвәл (иң беренче)* ***ялганчы кеше*** *белән әңгәмә кылма, чөнки ялганчы кешенең сүзе су өстенә ялган язган кебектер, ышанычы юктыр, якынны ерак кыйдыр, еракны якын итәр. Дәхи* ***ахмак вә надан*** *күренсә дә, вакыйгадан, зарардыр. Вә дәхи* ***комсыз*** *кеше белән аралашма. Чөнки ул кеше гел синнән өмет итеп кенә торыр. Янә дәхи* ***саран*** *кеше белән юлдаш булма. Чөнки саран кеше сиңа һичбер зарардан хали (буш ирекле) булмас. Әгәр дә аңар хаҗәтең төшсә, сине кимсетер вә хур кылыр. Хосусән, сәфәрдә саран кеше белән юлдаш булма. Дәхи вә* ***куркак вә җебегән*** *белән аралашма, чөнки куркак кеше белән һич имин булмассың”.*
- Чын дустыгызда нинди сыйфатлар булмаска тиеш? (ялган, наданлык, комсызлык-саранлык, куркаклык- җебегәнлек).

**4. Үгет- нәсыйхәтләр.**
- Ризаэддин Фәхреддин дуслык турында болай дигән:
- Адәм баласының шатлык вә кайгы вакытларында таяначак җире, файда күрсәтеп, файда күрәчәк урыны, дуслары булачактыр.
- Дине бөтен, гакылы камил, нәсел-нәсәбе асыл, фикере тугры, әдәбе җирендә булган кешеләрне табыгыз! Мойдый кешеләр авыруыгызда— дәва, сәламәтлегегездә — зиннәт, мәшәкатьләрегездә — таяныч, боек сәгатьләрегездә рәхәтләндерүче булырлар. Мондый кешеләр еракка китүегездә — хәлегезне кайгыртучы, якын

торганда сезнең хакыгызда догачы булырлар, байлыкка ирешү белән араны өзмәсләр, тарлыкка төшү белән аерылмаслар, дуслары — сүзләреннән артык фигыль вә гомерләрендә күрелер, олы изгелекләрне — кече дип санарлар, аз изгелекләрне олы күрерләр.

- Әгәр дә дөрес дусларыгыз булса, аларга ныгытып ябышыгыз, үзегездә шикаять итәрлек кимчелек булдырмагыз, аларны чын күңел белән сөегез, ахирәттә җыелу шарты белән, арагызны үлемнән башка нәрсә аермасын!
- Дуслык күрсәтүчеләрнең барчасы белән дә дус булмагыз, дошманлыгы бардыр дип уйлаган кешеләрегезнең барчасын да дошман санамагыз! Дуслыгының дөреслегендә шөбһә булган кеше белән дус булудан, һич дуссыз тору яхшы икәнлекне онытмагыз!
- Дусларыгызны шелтәләргә ашыкмагыз, туганнарыгыз вә кардәшләрегез белән бозылышуны җиңел күрмәгез; бәлки бу эшләрдә беркадәр сабыр булыгыз, чөнки ачуланышырга ният иткән кешеләрегез белән ачуланышмыйча вә бозылышмыйча, бер-ике көн кадәр сабыр итеп торсагыз — күп вакыт булыр, мондый ниятнең хата икәне ачылыр да, сабыр итүегез өчен үзегез дә шатланырсыз.
- Бик олы сәбәпләр булмаганда дуслар белән бозылышу — әдәпсезлектер. Шуның өчен аз гына нәрсәләр хакында дусларыгыздан аерылмагыз!
- Һәрвакыт хөрмәт күрсәтеп тору вә дөреслекне олылау сәбәпле дуслык көчәер. Шуның өчен дусларыгызга һәрвакыт ярдәмче вә аларга таяныч булыгыз! Кеше — бер ялгызы аз булса да, дуслары белән күп булыр. Дуслар — авырлык вә мәшәкать көннәрендә ярдәмче булсыннар өчендер.
- Бозык кешеләргә катышмагыз, алар юлына кермәгез, алардан бигрәк сак булыгыз, чөнки аларның иң ләззәтле эшләре бозыклык итү вә адәм балаларын һәлакәткә төшерү булыр. Адәм баласы ашамыйча вә эчмичә тора алмаган кебек, күңеле бозык булганнар да усаллык итмичә тора алмаслар. Әмма яхшы бәндәләр, тәмам боларның киресенчә булыр. Шуның өчен яхшы бәндәләр юлларына керегез вә алар белән дус булыгыз!
- Бозык кешеләргә катышу бик зарарлы булса да, алар белән дошман да булмагыз, бәлки вакыты җиткәнче йомшак мөгамәләдә булыгыз, бу сәбәпле аларның зарарыннан имин булырсыз!

**5. Психологлар: чын дуслыкның 13 кагыйдәсе.**

1) яңалыклар, әһәмиятле вакыйгалар белән уртаклашырга;
2) аның уй- фикерләрен, хисләрен “ярты сүз белән” аңларга;
3) кирәк чакта бик теләп ярдәм итәргә;
4) дустыңа син барында рәхәт булсын дип тырышырга;
5) дустыңа һәрвакыт ышаныч белән карарга;
6) дустың янында булмаса да, аны яманласалар- якларга;
7) алган әйберне, акчаны кире кайтарырга;
8) башка дус- иптәшләрен кабул итәргә;
9) вак- төяк белән аптыратмаска;
9) кеше барында дусның кимчелекләрен күрсәтмәскә;
10) дусның серен саклый белергә;
11) көнләшмәскә;
12) кирәкмәс җирдә өйрәтеп тормаска;

13) дусның вакытын сарыф итмәскә, теләкләрең хөрмәт итәргә.

**6. Изге Коръән китабыннан.**

- Аллаһы Тәгалә әйтте:

- ***“Мөселманнар бер- берсенә якын кардәшләр һәм туганнар”.***
- ***“Мөэминнәр (чын мөселманнар), әлбәттә, бер- берсенә кардәшләрдер. Кардәшләрегезнең арасын килештерегез, төзәтегез, Аллаһтан куркыгыз, мөэминнәр арасында фетнә, дошманлык салудан сакланыгыз, шаять, Аллаһтан рәхмәт ителерсез”*** */Хүҗ- җүрат: 10/.*

**7. Хәдисләр.**

- Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) хәдисен укып, үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с) әйтә:

- *“Инсаннар (кешеләр) җәмгыяте бер инсан (кеше) тәнендәге әгъзаларга охшар. Тәндә булган әгъзалар бер-берсенә ярдәмче булып торулары, берсе эштән чыкса, башкалары да шуннан зарар күрүләре кебек, инсаннар да бер-берсенә ярдәмче булып торырга һәм берсенә килгән һәлакәтне башкалары да уртаклашып сызланырга тиешләр”.*
- *"Бер кеше бер мөселманның дөньялык мәшәкатьләреннән бер мәшәкате хакында сөендерсә һәм юатса, Аллаһы Тәгалә аның ахирәт мәшәкатьләреннән бер мәшәкате хакында сөендерер. Бер кеше фәкыйрь һәм бурычланган кешегә дөньялыкта берәр төрле җиңеллек эшләсә (булышса һәм ярдәм бирсә) Аллаһы Тәгалә ул кешегә дөньяда һәм ахирәттә җиңеллек бирер. Бер кеше бер мөселманның гаебен һәм хата эшен пәрдәләсә, Аллаһы Тәгалә аны дөньяда һәм ахирәттә пәрдәләр. Үз кардәшенә ярдәм итүче кешегә Аллаһы Тәгалә ярдәм итәр".*

- Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз?
- Ислам безгә бер- беребезгә дусларча гына түгел, ә бәлки туганга караган шикелле якын итеп карарга, бер- беребезгә ярдәмләшергә куша.

**V. Рефлексия (Йомгаклау).**

**-** Дәреснең темасын искә тешерегез.
- Дуслык темасына карата нинди гыйбрәтләр алдыгыз? (Дусларны бик сайлап кына эзләргә кирәк- дустың синнән әйбәт булсын.).
- Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз? (Дуслык нык булсын өчен, үзеңә бик тырышырга кирәк).
- Чын дус сүзен сез ничек аңлыйсыз?
- Эчкерсез, аңа ихлас бирелгән.
- Холкы күркәм, күңеле яхшы булган кеше.
- Чын дус йөз елдан соң да дус булыр. Яхшы киңәш әйтсә генә дусны чын диеп була.
- Чын дус алдында мактамас, артта мактар, кирәк вакытта сине яклар.

**VI. Өйгә эш:** Өй эшен вариантлап бирәбез: 1) “Чын дус- нинди ул?” дигән темага җавап әзерләп килергә. 2) Чын дус турында хикәя, хәдисләрне эзләп табу.